**Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының «Карабаш шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге составына керүче Иркен авылы торак пунктында гражданнар җыены карары**

**2023 елның 14 декабрендәге** **2 нче номерлы карары**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы «Карабаш шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге составына керүче Иркен авылы торак пунктында гражданнар җыены

карар кабул итте:

2024 елда Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының «Карабаш шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге составына керүче Иркен авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән; суд тарафыннан эшкә сәләтсез дип танылган яки суд карары буенча иректән мәхрүм итү урыннарында тотылган затлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннары, срочный хезмәт хәрбиләре, мобилизация буенча чакырылган гаилә әгъзалардан тыш, 1000 сум күләмендә гражданнарның үзара салым салуын кертергә. Җыелган акчаларны Ибраһимов урамыннан Гафиятуллин урамындагы мәчеткә кадәр җәяүлеләр юлларын һәм тротуарларын төзүгә һәм ремонтлауга юнәлтергә.

**Гражданнар җыенында рәислек итүче,**
**“Карабаш шәһәр тибындагы поселогы "**
**муниципаль берәмлеге башлыгы** **И.И.Җәләев**